Арбор төп белем бирү мәктәбе

**«Ягез әле, кызлар!»**

**(бәйрәм кичәсе)**

**Төзеде: Мифтахова Р.Б.**

**2021**

А.б. Көннең яктылыгы – кояшта,күкнең матурлыгы – йолдызларда, җирнең гүзәллеге – кызларда. 8 март хатын – кызларны олылау көне, матурлык бәйрәме. Әлеге бәйрәм башка бәйрәмнәрдән яктырак та, җылырак та, мөлаемрак та шикелле. Шуңа күрә дә менә бу бәйрәмне кешелек дөньясы 1913 нче елдан ук бәйрәм итеп килә. Сезне бөтен җир йөзен бизәгән яз бәйрәме – Халыкара хатын – кызлар көне белән тәбриклибез. Сезгә озын гомер,елмаеп балкыган кояш матурлыгы,укуыгызда зурдан – зур уңышлар телибез.

Ә хәзер кичәбезне башлап җибәрергә рөхсәт итегез.

**1.“Таныш булыйк”**

А.б. Шулай итеп, бәйгенең беренче бүлеген башлыйбыз. Ул «Таныш булыйк!» дип атала. Бер – берсен сәламләү өчен сүзне үзләренә бирик. Рәхим итегез!

**2. “Тәлинкәдә нәрсә?”** конкурсы. Командалардан 1әр кыз чакырыла. Күзен бәйләгән килеш ул тәлинкәләргә салынган он, шикәр комы, дөге, карабодай, тары, тозны кул белән генә капшап нәрсә икәнен белергә тиеш.

**3. Конкурс “Интеллектуаллар”** Командаларга 3 әр сорау бирелә. Бер дөрес җавап өчен 1 балл.

1. Сакалы бар, акылы юк, ул нәрсә? (Кәҗә)

2. Үзе суфый, үзе урлаша. Әле тотсаң тырнаша. (Песи)

3. Кош тугел койрыклы. (Балык)

4. Мамык юрган, кат-кат сырган. Үзе бик суык. ( Кар)

5. Җәй буе ял итәләр, кышын тәпиләп китәләр ( Чаңгы)

6. Җәеп тотсаң, табактай,

Җыеп тотсаң, таяктай (зонт)

**4. Конкурс “Кем чибәррәк?”**

Җир йөзендә үз-үзенә бәя бирә белүче кешеләргә яшәргә җиңелрәк икән. Психологлар фикеренчә, үз-үзенә дөрес бәя бирә алган кешеләр бәхетле була алалар. Командадан берәр кеше чакырыла. Һәр гүзәл зат үзенең иң-иң булуын расларга тиеш. Ул көзгегә карап жюрига һәм тамашачыларга үзенең нинди булуын сөйләп бирә. Конкурсның төп шарты 2 минут эчендә кызлар безне һәм үзләренең иң яхшы булуларына ышандырырга тиешләр. Ләкин көләргә һәм бер үк сүзләрне кабатлау тыела. Жюри кайсы кызның иң яхшы чыгыш ясавын бәяли.

**5. “Аңла мине”** уены. Командаларның капитаннары килеп кәгазь битенә язылган эшне жестлар ярдәмендә командадагы икенче иптәшенә, аннан ул өченчесенә аңлатырга тиеш. Иң соңгы кыз ни хакында сүз барганын әйтеп бирә. Команданың башка члennары бу арада башка бүлмәдә торалар. Аларны чакырып кертәләр. Шул рәвешле бер команда “Пилмән ясау”, икенче команда “ Токмач җәю”не башкаларга аңлата.

**6.“Сәхнәләштереп күрсәт”. Командалар бирелгән язуга карап 2 минут эчендә әлеге вакыйганы сәхнәләштереп күрсәтәләр.**

1. Шәмәрдәннең поездлар узу станциясе. Юлларны күзәтүче, шлагбаумны регуляцияләп торучы Сәлим бабай өрә-өрә, чапылдатып, шикәр суырып чәй эчә. Стенада сәгать йөри. Еракта

тонык кына паровоз кычкыртканы ишетелә. Сәлим бабай авыр сулап урыныннан кузгала, шулчак аның утырган урындыгы кинәт авып китә. Паровоз тавышы исә көчәя бара. Станцияне шаулатып поезд узып китә. Кинәт будкада телефон шалтырый. Трубканы алган Сәлим бабай эндәшмәүләренә җенләнеп, шапылдатып трубканы куя да сиртмәле караватка барып ята. Караватбик зәһәр итеп итеп шыгырдап куя. Шулчак урамнан машиналар кычкыртканы ишетелә. Сәлим бабай шлагбаумны ачарга онытканын аңлап сикереп тора. Шлагбаум шыгырдап күтәрелә, машиналар әкренләп поезд юлы аша чыгып китәләр. Сәлим бабай бөтен дөньясына зарланып, кабат җылы урынына барып кунаклый. Караватт кабат бик зәһәр итеп итеп шыгырдап куя. Караватка барып яткан Сәлим бабай бер мизгел дә үтми гырлап йокыга китә.

2. Тын гына авыл киче. Су буендагы бакаларның кычкырган тавышлары ишетелә. Кәтүк түтиләрнең өй нигезләрендәге мунча сиерчыклары сайраганы ишетелә. Капка төбендә Кәтүк түтинең кызы Үринә һәм аның сөйгәне Степан сөйләшеп утыралар. Нәрсә турындадыр бик каты бәхәсләшәләр. Шулчак Үринәнең бик нык ачуы чыгып, чатнатып Степанның яңагына китереп бирде. Ачуыннан Степан капка төбендәге эскәмияне төртеп аударды. Шулчак койма башындагы мәчеләрнең зәһәр чинаулары ишетелде. Степанның кыланышыннан курыккан Үринә чырылдап җибәрде. Тавышка авыр капканы шыгырдатып ачып аксак-туксак Үринәнең әтисе килеп чыкты да каты итеп тамак кырды. Абзардагы маллар йокламаган иде, күрәсең. Сыер да мөгерәп куйды, бәкиләр тавышы ишетелде, аларга дуңгызлар кушылды. Бу тавышка йөдән чыккан Гөрпинә түти баскычка абынып егылды. Үринә белән аның әтисе икәүләшеп аның янына йөгерделәр. Аны күтәреп өйгә алып кереп киттеләр. Ә Степан, берни булмагандай, сызгыра-сызгыра кайтып китте.

**7. “Сыер савучылар”** конкурсы. Һәр командадан 2шәр кыз чакырыла. Кызлар мөмкин кадәр тиз арада күбрәк күләмдә сөт савып алырга тиешләр. Сөтләр бутылкага тутырыла, бутылкага медицина перчаткасы кигертелә. Перчаткаларның башлары нечкә энә белән тишелә. 2 минут эчендә кем күбрәк сөт савып ала.

**8. “Бәрәңге җыю”** конкурсы. Һәр командадан бер кыз чакырыла. Мөмкин кадәр тиз арада бәйләнгән күз белән бәрәңгене җыеп бетерәсе.

**9. “Эстафета”**. Кулда себерке, башта китап, уң кулда тәлинкә. Билгеләнгән җирдән әйләнеп киләсе.

**10. “Осталык”** конкурсы.

-салфетка төрү

- йомыркадан ромашка чәчәге ясау.

**11. “Кара-каршы” конкурсы.** Командалар җыр буенча көч сынаша. Беренче команда башлый, ә икенче команда соңгы хәреф нинди була шуннан җыр башларга тиеш.

**12. “Сүз төзү”.** “Карлыган” сүзеннән кем күбрәк сүз төзи ала 2 минут эчендә.

**13. “Бию” конкурсы.** Кәгазьдә язылган бию төрен команда белән биисе.

**14. “Сәхнә йолдызлары” (өй эше)** Скетч күрсәтү.

Егет. Кара кашларыңның канатларын

Карлыгачлар бүләк иттеме?

Йөзең нурлы, әллә бит очыннан

Таң кояшы үбеп киттеме?

Кайдан синдә мондый гүзәллекләр,

Буй – сыннарың сылу, сөйкемле.

Уңган – юмарт та син, тыйнак та син,

Җир – әнкәнең үзе шикелле.

Егет. Бәйгебезнең 1 ярышы шигырь юллары белән бәйле. Бәйгенең шарты: без кызларга конвертлар әзерләдек. Конвертлар эченә сүзләр язылган кәгазьләр салынган. Шул сүзләрне кертеп, кызлар шигырь язырга тиешләр. Менә сезгә кызлар конвертлар, алыгыз. Сезгә 5 минут бирелә. Башладык.

1 командага

Язның матур бер көнендә

Чыктым уйнап керергә.

Шул минутта насыйп булды

Кыр казларын күрергә.

2 командага

Бакчадагы түтәлдә

Чәчәк атты гөлләрем.

Нәкъ шул мизгелдән башлап,

Ямьләнделәр көннәрем.

3 командага

Тау башыннан карап тордым:

Инешләр – Идел сыман.

Быел безнең якларга да

Аккошлар килер сыман.

Кыз. Безнең кызлар шигырь төзегән арада, егетләр белән бер уйнап алыйк әле. (5,6,7 класслардан 1 егет чыга һәм шул егет күзе бәйләнгән кие, кыз рәсеме ясый). Егетләрнең осталыклары, тырышлыклары жюри әгъзалары белән исәпкә алына һәм инде кызлар командасына очколары туплана. Шуңа күрә, егетләр, сезгә дә бик каты тырышырга туры килер.

Егет. Кызларыбызның вакытлары бетте. Хәзер инде алар сүзләрдән нинди шигырь килеп чыкканын укып китәрләр.

Кызлар шигырь укыйлар.

Кыз. 3 бәйгебез – “Иң оста пешерүче”. Хәзер кызларның көнкүрештә, аш-су әзерләүдә тапкырлыгын сынап карарбыз. Киңәшләрне белгән кызлар җөмләне тәмамлый. (Сораулар командаларга бер-бер артлы бирелә).

1. Тоз дымланмасын өчен, ... (тоз савытына берничә бөртек дөге ярмасы салырга кирәк).

2. Шулпа тәмле булсын өчен, ... (итне салкын суга салып пешерергә кирәк. Ит пешеп җитәрәк, шулпага коры табада кыздырган кишер белән суган салсаң, шулпа тагын да тәмлерәк һәм матуррак була).

3. Камыр кулга ябышмасын өчен, ... (кулны көнбагыш мае белән майларга кирәк).

4. Бавыр тәмле, йомшак булсын өчен, ... (кыздырганчы 1-2 сәгать сөттә тоталар).

5. Балыкның тәңкәсе яхшырак купсын өчен, ... (тиз генә кайнар суга салып алалар).

6. Бүрттергән чакта дөге изелмәсен өчен,... (кайнап чыккач, суга 2-3 кашык сөт салалар).

7. Кайнатканда сөт ташымасын өчен,... (савыт кырыен майларга кирәк).

8. Сөт кайнаткан савыт тизрәк юылсын өчен, ... (аны башта - салкын, аннары җылы су белән юалар).

9. Сөт тизрәк кайнасын өчен,... (савытка бераз шикәр комы салалар).

Кыз. Кызлар алар бөтен яктан да уңган – булган булырга тиеш, шулай бит. Менә хәзер, кызлар, сезгә чәчәкләр ясарга туры килер: кем күбрәк, матурырак һәм тизрәк булыр. (кызлар чәчәкләр ясый).

Конкурс “Интеллектуаллар” Командаларга сорау бирелә. Бер дөрес җавап өчен 1 балл.

1.Һәркемдә дә бар. (исем)

2. Күңелсезгә - юаныч, күңеллегә куаныч. (җыр)

3. Ялгыз гына ашалмый, аннан башка эш бармый. (тоз)

4. Үзе су, үзе каты. (боз).

5.Борынгы заман сәгате. (әтәч)

6. Нәрсә өстәл янында бик кирәк? (авыз)

7. Нинди савыттан эчеп булмый. (буш)

8. Сыер ни өчен ята? (утыра белмәгәндә)

9. Кара мәче нинди ишектән керә? (ачык)

10. Ашлыкны ни өчен чәчәләр? ( утыртып булмаганга)

11. Нәрсәне әзерләп була, ашап булмый. (өстәлне)

12. Күлмәкне урталай яргач, нәрсә була. ( күл+мәк)

13. Ак кыныдыр үзләре, ялтырыйдыр күзләре. (йолдыз)

14. Казанның уртасында ни бар? (з авазы)

(конц ном)

-Тапкыр сүз, җор теллелек, зирәклек хас безнең халыкка. Менә бүгенге кичәдә дә бирелгән сораулар алдында югалып калмыйча, кызлар үзләренең белемнәрен, тапкырлыкларын күрсәтерләр дип ышанып калабыз. Сезгә ике ситуация.1) К е ше белэн тулы ав тобуста сезнен ор-яна блузкагызга кемдер томат согы тукте.Сез нихэл итэсез?К кинэшлэшеп 1 жавап бирэ.2)Сезнен туфлиегызнын укчэсе тоште ,барасы жир бик ерак.

(стих Азамат .Татар кызы...Бу исемдә

Күпме тылсым, күпме сер!

Нечкә билле бу сылуга

Сокланып син бакчы бер!

Иман нуры балкый аның

Ай кебек йөзләрендә

Зыялылык, инсафлылык

Гап-гади сүзләрендә

Тал чыбыгы кебек нечкә билле,

Яз кояшы кебек сөйкемле.

Дөньяларда иң-иң гүзәл зат та,

Татар кызы гына шикелле

Э хэзер художниклар ярышы.Бодай бортеклэреннэн 8 мартка рэсем ясарга.( конц)

-Килэсе конкурс.”Буш суыткыч “ дип атала.Шушы суз тезмэсенэ ке ргэн хэрефлэрне остэп ризык исемнэре язарга.татарча сузлэр булса бигрэк тэ хуплы булыр иде.2шэр кыз.кем тизрэк?

-Э хэзер ой эшен тикшерэбез.Кызларга кара каршы эйтер очен такмаклар эзерлэргэ кушылган иде.

- Стих Күзләреңнең каралыгын

Шомыртлардан алдың мәллә?

Су буенда  гына үскән

Зифа талдай синең гәүдәң.

Үкчәләрең җырын тыңлап,

Хыялларга бирелеп китәм

Әй, син, горур татар кызы,

Кем бар синдәй бүтән

-Аш-су олкэсендэ дэ бер конкурс кирэктер.Булган ризыклардан тиз салат эшлэргэ.

-Кызлар салат эзерлэгэн вакытта ярыш-сэнгэтле шигырь укучылар .

“Икеле алмадым “,дип

Кайтты да ул мактанды.

Бик куанды энисе,этисе бик шатланды.

Лэкин шатлык бик тиз утте.

Кайгы минуты.

Малайнын кузен каплады

Кара хурлык болыты.

Кондэлеген карадылар

Мактану-ялган иде

Малай актыгы ул конне

3 берле алган иде.

Хормэтле кызлар,э хэзер “сорауларга- жавап “ дигэн бэйге.

1.нэрсэ ул бэхет?

2.килэчэктэ кем булырга телисен,ни очен?

3.сезнен очен бу тормышта кем олге булып тора?

4.яраткан шогелегез турында сойлэргэ

5.мэктэп тормышында нэрсэ ошый?

6.якын дустыгыз турында сойлэргэ.

- килэсе бэйге «Артистлар” дип атала. төрле ситуацияләр күрсәтергә:

Сезне эт тешләде.

Бармагыгыз ишеккә кысылды.

Сез карбыз ашыйсыз.

Энәгә утырдыгыз.

Туңдырма ашыйсыз.

Әминәне бии-бии сөйләргә. .